КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 июнь г.Казань № 501

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 2 май, 358 нче карары белән расланган 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 2 май, 358 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 сентябрь, 872 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 3 яшьтән 7 яшькә

кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Респуб-ликасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «шәхси счетка» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «финанслауның иң чик күләмнәрен Министрлыкка аның заявкалары буенча җиткерүгә чыгым расписаниесен Казначылыкка кертә» сүзләрен «агымдагы финанс елына субсидияне финанслауның иң чик күләмнәрен аның заявкалары буенча Министрлыкка җиткерә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Министрлык агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидияне финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң биш эш көне эчендә агымдагы финанс елына субсидияне финанслауның иң чик күләмнәрен гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерү өчен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба - Үзәк) җиткерә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«7. Министрлык Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасын кулланып Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән срокларда һәм формалар буенча хисаплар тапшыра.»;

8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин